| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.07.2022** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1794** |

Эш режимын үзгәртү турында

Зеленодольск муниципаль районы белем бирү оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Башкарма комитет

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 01 сентябреннән түбәндәге мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә 12 сәгатьлек эш режимын 10,5 сәгатькә үзгәртергә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Гомуми үсеш төрендәге 3 нче номерлы «Башак» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Октябрь поселогында «5 нче номерлы «Тиенкәй» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Большие Ключи авылының «Гомуми үсеш төрендәге 28 нче номерлы «Рябинка» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогының «Гомуми үсеш төрендәге 36 нчы номерлы «Нараткай» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогының «Катнаш төрдәге 42 нче номерлы «Алчәчәк» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «48 нче номерлы «Алтынчәч» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогының «51 нче номерлы «Тополек» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.

2. Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә:

- ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәгълүмат бирергә;
- мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренә хәбәр итәргә;
- штат расписаниеләре төзергә;
- 2022 елга муниципаль биремнәргә үзгәрешләр кертергә;
- Уставларына, башка хокук билгели торган документларга, учреждениеләрнең рәсми сайтларына урнаштырылган мәгълүматка үзгәрешләр кертергә;
- 2022 елга учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарына үзгәрешләр кертергә.

3. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-икътисади хезмәте» МКУ җитәкчесенә ата-аналар өчен түләүне исәпләргә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев